Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына 2020 елда
гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә
АНАЛИЗ

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына (алга таба – Министрлык) 2020 елда гражданнардан **2251** мөрәҗәгать кергән, бу 2019 ел белән чагыштырганда (958 мөрәҗәгать) 3 тапкырга артыграк. Шулардан 2202 мөрәҗәгать язма рәвештә, шул исәптән Интернет кабул итү бүлмәсе аша - 1004 мөрәҗәгать кергән.

Татар телендә 3 мөрәҗәгать кергән.

Гражданнарны кабул итү Министрлык җитәкчелеге тарафыннан билгеләнгән көннәрдә расланган график нигезендә гамәлгә ашырыла.

Министрлык җитәкчелеге тарафыннан турыдан-туры 31 кеше кабул ителгән. Видеоконференцэлемтә режимында гражданнар 3 тапкыр кабул ителгәннәр, шуларның икесе министр катнашында узган. Алар барышында 17 кеше үз сорауларына җаваплар алганнар. 1 кеше телефон аша үз сорауларына җаваплар алган.

Килеп ирешкән корреспонденция мөрәҗәгатьләрдә күтәрелгән мәсьәләләр һәм Министрлык компетенциясен исәпкә алып карала.

Шикаятьләр, гаризалар һәм тәкъдимнәр түбәндәге тематикалар буенча кергән.

**Саклану, куркынычсызлык, законлылык - 899, (36,38%).**

«Иминлек һәм хокук тәртибен саклау» тематикасы буенча 530 сорау керде. Аларның 462се санитар-карантин контролен тормышка ашыру, аерым алганда яңа коронавирус инфекциясе таралуны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар белән килешмәү белән бәйле.

242 мәсьәлә суд системасына кагылышлы, шуларның 237се - федераль һәм җәмәгать судьялары һәм аларның аппаратлары эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр һәм шикаятьләр.

118 мәсьәлә прокуратура, юстиция органнары, нотариат һәм адвокатура эше белән бәйле.

Җәзаларны үтәү органнары эшчәнлегенә бәйле рәвештә 9 сорау керде.

**Социаль өлкә - 665 (26,91%).**

«Сәламәтлек саклау. Физик культура һәм спорт. Туризм» тематикасы буенча **285** мөрәҗәгать керде.

Сәламәтлек саклау өлкәсенә караган 285 мөрәҗәгатьнең 215е халыкның санитар-эпидемиологик иминлегенә кагылышлы: җәмәгать урыннарында битлек һәм перчаткалар кию таләбе белән килешмәү; шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү таләбе. 70 мөрәҗәгать медицина учреждениеләре һәм аларның хезмәткәрләре эше һәм саф һавада йөрүнең әһәмияте турында.

«Мәгариф. Фән. Мәдәният» тематикасына караган мөрәҗәгатьләр – **145** берәмлек. Аларның 116 сы балигъ булмаганнар катнашында хезмәт эшчәнлеген башкаруга рөхсәт бирүгә кагыла, 29 мөрәҗәгать балалар бакчалары эше һәм укучыларны дистанцион укыту белән бәйле проблемалар, мәдәният объектлары эшен яңарту турында.

«Гаилә» тематикасы буенча **56** мөрәҗәгать керде. Алар балага һәм күп балалы гаиләләргә алиментлар, пособиеләр һәм компенсацияләр түләү белән бәйле.

«Социаль тәэмин итү һәм социаль иминиятләштерү» тематикасын үз эченә алган **122** мөрәҗәгать керде. Шул исәптән балалары булган гаиләләргә, күп балалы гаиләләргә, авыр хәлдә калган гражданнарга, эшсезләргә, аз керемле гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү, түләүсез юридик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре турындагылар.

**57** мөрәҗәгать «Хезмәт һәм халыкның мәшгульлеге» темасына кагылышлы. Нигездәалар эшсез гражданнарга социаль түләүләр мәсьәләләре.

Шулай итеп, 2019 елда әлеге тематикалар буенча барлыгы 300 мөрәҗәгать кергән.

**Дәүләт, җәмгыять, сәясәт - 557 (22,54%).**

Әлеге тематик блок буенча кергән мөрәҗәгатьләрдә гражданнар башкарма хакимият органнары, муниципаль органнар һәм вазыйфаи затлар эшчәнлегенә бәя биргәннәр.

**Икътисад - 303 (12,26%).**

2020 елда бу тематикага кагылышлы мөрәҗәгатьләр дә шактый булды (2019 -117 берәмлек). Иң күп сораулар гражданнарда сәүдә, төзелеш, хезмәт күрсәтү объектлары, транспорт хезмәте күрсәтү эшчәнлеге тукталган чорда туган.

**Торак-коммуналь өлкә - 47 (1,90%).**

Әлеге тематикага кагылышлы сораулар 2019 елдагыдан кимрәк булды (2019 - 69 берәмлек).

Анализ күрсәткәнчә, мөрәҗәгатьләр COVID-19 яңа коронавирус инфекциясе таралган чорда - 2020 елның апрель-июнь айларында күп кергән. 1055 мөрәҗәгать бу чорда кабул ителгән чикләү чаралары белән бәйле мәсьәләләрне үз эченә алган. Бу барлык корреспонденциянең 45% ын тәшкил итә.

Гражданнардан Министрлыкка кергән барлык мөрәҗәгатьләр дә «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә каралалар.

**Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының 2020 елда гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эше турында**
**СТАТИСТИК БЕЛЕШМӘЛӘР**

| Министрлык/Ведомство | 2020 елда гражданнардан кергән барлык мөрәҗәгатьләр* | 2019 елда гражданнардан кергән барлык мөрәҗәгатьләр | Телдән мөрәҗәгать итүләр (шәхсән кабул итү һәм телефон аша алынганнар) | Шул исәптән җитәкче тарафыннан шәхсән кабул ителү | Шул исәптән видеоконференцэлемтә системасы аша кабул ителү | Язма мөрәҗәгатьләр | Шул исәптән Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән** | Контрольгә алынган | Урынга чыгып тикшерелгән | Уңай хәл ителгән |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 2251 | 958 | 49 | 4 | 17 | 2202 | 1004 | 2251 | - | 51 |

***Барлык мөрәҗәгатьләр = язма мөрәҗәгатьләр һәм телдән мөрәҗәгать итүләрнең** суммар күләме.
****Интернет кабул итү бүлмәсе** язма мөрәҗәгатьләр исәбенә керә.